ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

КАРАР

2019 елның 5 нче июле №2

## Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендә чыккан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2131-ФЗ номерлы законы, Яңа Кишет авыл җирлеге Уставы һәм хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашуда Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге халкының хокукларын тәэмин итү максатында 2018 нчы елның 30 октябрендә чыгарылган 1 номерлы Совет караы белән расланган "Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә"г яраштырып, карар бирәм:

1." Яңа Кишет авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын" 2019 елның 5 августына билгеләргә.

2. "Яңа Кишет авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар"ны Арча муниципаль районы, Яңа Кишет авыл , Дуслык урамы , 100 а нчы йорт адресы буенча 2019 елның 5 августында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

3. Гражданнарның Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрен һәм җәмәгать тыңлауларында катнашу турында язмача гаризаларын 5 августның 10.00 сәгатенә кадәр Арча муниципаль районы, Яңа Кишет авыл , Дуслык урамы, 100 а нчы йорт адресы буенча җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) , Арча муниципаль районының рәсми сайтында(arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты; ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты; ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт; ТР, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Муниципаль берәмлегек җитәкчесе Арсланов Т.А.